РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Уразаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района
ул. Н.Бадертдинова, д. 35, Азнакаевский
район, с.Уразаево, 423303, тел./факс
(885592)43-5-55
E-mail: Uraz.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Уразай авыл җирлеге
башкарма комитеты
Н.Бадертдинов ур., 35 йорт, Азнакай
районы, Уразай авылы, 423303
тел./факс (885592)43-5-55
E-mail: Uraz.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**6 апрель 2023 ел** **№ 6**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 17 ноябрендэге 23 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә үзгәреш кертү турында (2018 елның 3 маендагы 9 номерлы, 2019 елның 4 апрелендәге 25 номерлы, 2019 елның 17 октябрендэге 39 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законныц 16 статьяның 2 пунктыныц икенче абзацы үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 17 ноябрендэге 23 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә (2018 елныц 3 маендагы 9 номерлы, 2019 елның 4 апрелендәге 25 номерлы, 2019 елның 17 октябрендэге 39 номерлы карарлар редакциясендә) 2.14 пунктында «бер ай һәм

өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн һәм утыз көннән артык» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча: http//aznakayevo. tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык А.М.Шәрифуллина